Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ


12+

№16 (109)

29 май 2014 ел







Влад Михневский һәм редакция архивы фотолары

# Шәхеснең бөеклеге – мирасында!

«Зур галимнәр берничә төрле була. Фәнни җәмгатьчелектә бериш галимнәр зур фәнни ачышлар ясый. Һәм бу ачыш үз артыннан бик күп яңа ачыш ияртеп килә. Кайбер галимнәр, киресенчә, укучылар тәрбияли. Бу укучылар яңа ачышларга юл ачып торган була. Өченче төр галимнәр, мин аларны бик акыллы, алдан күреп эш йөртә торган зирәк галимнәр дияр идем, алар – җәмгатьчелекнең фикерен үзгәртүче галимнәр. Миркасыйм Госманов үзе сайлаган төрки татар тарихы юнәлешендә дә, Татарстанда фән үсеше ягыннан да фәнни җәмгатьчелек фикерен үзгәрткән кеше». ***Дания Заһидуллина.***

*Дәвамы 3 биттә*

## Вакыйгалар эзеннән

**26 МАЙ** көнне **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ** күчмә формада – Фундаменталь медицина һәм биология институты бинасында **УЗДЫ**. Экскурсияне шул институт директоры А.Киясов үткәрде. **И.ГАФУРОВ** сүзләренчә, ремонт эшләре бу бина белән генә чикләнеп калмаячак. Якын киләчәктә А.М.Бутлеров ис. химия институты, Инженерия институты, Экология һәм география институтында да төзекләндерү эшләре башкарылачак. Административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** контроль йөкләмәләрнең үтәлеше белән таныштырды. 2014-2015 уку елына абитуриентларны кабул итүгә әзерлек эшләре турында Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **С.ИОНЕНКО** сөйләде. Быел документларны 20 июньнән кабул итә башлаячаклар. Үзәк Азия илләрендә университет кабул итү имтиханнарын күчмә формада алачак. Алар 16 июньдә үк башланачак. КФУның приоритетлы юнәлешләре буенча аспирантурада уку өчен грант конкурсына гаризалар тапшыру турында Фәнни-тикшеренү эшчәнлеге идарәсе җитәкчесе **Н.ЖУРАВЛЕВА** җиткерде. Аның сүзләренчә, мәгълүмат Россия төбәкләре һәм чит илләргә җибәрелгән һәм кызыксынучылар да бар икән инде. Алга таба сүзне Белем бирү ресурсларын үстерү департаменты җитәкчесе **Г.ИВШИНА** алды. Ул «КФУда электрон белем бирү системасы» проектын гамәлгә ашыру турында сөйләде.

• • • •

**23-24 МАЙ** көннәрендә КФУның Чит ил студентлары һәм аспирантлары советы инициативасы белән инде традициягә әверелгән **«АФРИКА КӨННӘРЕ»** чарасы **БУЛДЫ**. Африка илләреннән килеп, Казан вузларында укучылар мини-футбол ярышында көч сынаштылар. «Африканың бай мирасы» исемле фотокүргәзмә оештырылды. Кич белән гала-концерт узды.

• • • •

Яр Чаллы институтында Өстәмә белем бирү үзәгенең **«ҺӨНӘРИ БАГЛАНЫШЛАР ӨЛКӘСЕНДӘ ТӘРҖЕМӘЧЕ»** программасы буенча укыган **48 СТУДЕНТКА** тантаналы рәвештә **ДИПЛОМ ТАПШЫРДЫЛАР**. Хәзер алар үзләренең белемнәрен тормышта куллана алачак.

• • • •

Шушы көннәрдә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында 2014-2015 уку елына яшь галим һәм укытучыларга **ДААД** академик алмашуның **ГЕРМАНИЯ ОЕШМАСЫ СЕРИТФИКАТЛАРЫН ТАПШЫРУ ТАНТАНАСЫ БУЛДЫ**. Әлеге грант Республикабыздан барлыгы 54 кешегә бирелде. Бәхетлеләрнең 24е – КФУда белем алучылар!

• • • •

**26 МАЙ** көнне **«СТУДЕНТЛАР ЯЗЫ – 2014»** Республика студентлар иҗаты фестиваленең **ГАЛА-КОНЦЕРТЫ БУЛДЫ**. Анда КФУ Гран-при бүләгенә лаек дип табылды. Уку йортыбыз инде дүртенче ел рәттән бу өлкәдә беренчелекне бирми. Бу университетыбызда белем ала торган 40 мең студентның уртак җиңүе! Тәбрик итәбез!

• • • •

Шушы көннәрдә **КФУ**да Болон университетының Үзәк-Көнчыгыш Европа һәм Балканны тикшерену үзәге директоры, сәясәт һәм сәясәт фәннәре мәктәбе тарихы профессоры **СТЕФАНО БЬЯНКИНИНЫҢ ЛЕКЦИЯЛӘР КУРСЫ БАШЛАНДЫ**.

• • • •

Күптән түгел Ижау шәһәрендә **ШАХМАТ** буенча Россия яшьләренең **III ҖӘЙГЕ СПАРТАКИАДАСЫНЫҢ II ЭТАБЫ УЗДЫ**. Анда ИТИС югары мәктәбенең 2 курс студенты Р.Мөхәмәтгалиева беренче урынга лаек булды. Быел ул ФИДЕ рейтингы буенча Татарстанның иң яхшы 10 шахматчысы исемлегенә дә керде.

***Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды***

● Заман таләбе

# Табиб та, биолог та!

Алинә САДЫЙКОВА

Бу атнада ректорат гадәти булмаган, үзгә шартларда узды. Ул Фундаменталь медицина һәм биология институтының Карл Маркс урамында урнашкан бинасында үтте. Мондый үзгәрешнең сәбәбе – ректорат вәкилләрен бирегә башкарылган ремонт эшләренең нәтиҗәсе, Симуляцион медицина үзәгенең заманча җиһазландырылган лабораторияләре, укыту классылары белән таныштыру.



Влад Михневский фотолары

Ил күләмендә алдынгы юнәлешләрне куәтләү максатыннан, Казан федераль университетында яңа проектлар, идеяләр тормышка ашырыла. Медицина һәм биологик технологияләр аеруча алга киткән өлкәләрдән санала. Хәзерге көндә 2013 елда ачылган Фундаменталь медицина һәм биология институтының максаты – фундаменталь тикшеренүләргә нигезләнеп, заманча дөньяви стандартларга туры килә торган биология һәм медицина белеме бирү.

Татарстанда медицина фәненең алга китешенә КФУда әзерләнгән белгечләр зур йогынты ясаячак. Алар яңа буын табиблары булачак. Ә уку йортының, югары квалификацияле белгечләр әзерләү өчен, бөтен мөмкинлекләре дә бар. Әлеге институт күп төрле белгечләр: табиблар, стоматологлар, табиб-генетиклар, табиб-рентгенологлар һ.б. әзерләүне максат итеп куя. Шулай ук Россиянең 200дән артык медицина оешмаларында, дөньяның иң яхшы фәнни үзәкләрендә стажировка үтү мөмкинлеге дә бар. Сәламәтлек саклау өлкәсендә этрафлы белгечләр әзерләү һәм югары сыйфатлы уку процессын оештыру өчен, күп профильле клиника булдыру зарур. КФУ студентлары өчен мондый мәйдан булып 2 номерлы Республика клиник хастаханәсе хезмәт итә. Күптән түгел РКБ-2 базасында заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән трансляцион медицина үзәге эшли башлады.

Шулай ук «ФАРМА 2020» программасын тормышка ашыру кысаларында фармацевтика буенча фәнни белем бирү үзәге дә ачылды. Бирегә инновацион дарулар һәм субстанцияләр эшләп чыгару белән шөгыльләнәләр. Бу процесска химия, биология, медицина һәм фарматехнология буенча белгечләр җәлеп ителде.

Фундаменталь медицина һәм биология институтын тәмамлаган белгечләр хезмәт базарының төрле өлкәләрендә үз урыннарын таба. Алар алган белемнәрен медицина, биотехнология һәм азык-төлек җитештерү, нефтехимия сәнәгате, табигатьне саклау оешмаларында, Эчке эшләр министрлыгының криминалистика бүлекләрендә, ландшафт дизайны фирмаларында куллана алачак. Киләчәктә бөек галимнәр әзерләүдә кочләрен сынап карарга теләүчеләр өчен, институтта педагогик белем бирү дә каралган.



**Фундаменталь медицина һәм биология институты ул:**

- 13 фундаменталь медицина һәм биология кафедрасы;
- 30 фәнни-тикшеренү лабораториясе (аларның икесе халыкара) һәм клиник база;
- җәйге практика узар өчен 4 уку-фәнни базасы, шул исәптән Ак диңгездә;
- уникаль Зоология һәм Ботаника музейлары;
- кече инновацион предприятиеләр;
- ботаника бакчасы.

● Җиңүләр һәм табышлар



Влад Михневский фотосы

# Фәнгә гашыйклар!

26 май көнне КФУ студентлары арасында иң яхшы фәнни эш конкурсына нәтиҗә ясалды.

Университет бу конкурсны инде алтынчы тапкыр үткәрә. Быел 192 студентның эше бәйгенең икенче турына үткән. Шуларның 134е – социогуманитар фәннәр, калган 58 эш табигый фәннәр юнәлешенә багышланган иде.

Фәнгә гашыйк студентларны уку йортыбыз администрациясе: уку-укыту эшләре буенча проректор Р.Минзарипов, социаль һәм тәрбия эшләре буенча проректор А.Межведилов сәламләде.

Бүләкләү тантанасы исә бик матур һәм масштаблы оештырылган иде. Табигый фәннәр юнәлеше буенча – 18 студент, социогуманитар юнәлеш буенча 19 шәкертнең эшләре югары бәягә лаек булды.

Чара ахырында барлык җиңүче һәм лауреатларга күңелле хәбәр җиткерделәр: бирегә катнашучыларга акчалата премия формасында өстәмә бүләк каралган. Өченче урынлы дипломга ия булучылар – 4 мең, икенче урынлылар – 5 мең, беренче урынны яулаучылар 6 мең алачак.

Махсус номинациядә урын алучылар 3 мең белән бүләкләнде. Алай гына да түгел, фәнни җитәкчеләрне дә читтә калдырмаганнар. Кемнәрнең студентлары үзләрен яхшы яктан күрсәткән, шул остазларга да 4 мең күләмендә өстәмә бүләк биреләчәк.

● Мөнбәр

# Без – бер бөтен!

26 майда КФУ ректоры Ильшат Гафуров академик төркем кураторлары белән очрашты.



Кураторлар уку йортында корпоратив мәдәният үсешенә зур өлеш кертә. Бүгенге көндә КФУда беренче һәм икенче курсларда 350 куратор эшли, алардан тыш институтларның тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары тәрбия процессында мөһим роль уйный. Ректор, хезмәттәшләренә мөрәҗәгать итеп, уку йортының үсеш тенденцияләре, конкурентлыкка сәләтлелек программасын тормышка ашыру нечкәлекләре белән якыннан таныштырды. «Сез КФУга белем алырга килгән яшьләрне тәрбияләүдә төп көч булып торасыз. Рейтингларда әлеге күрсәткеч юк, ләкин җәмгыятьтә барган сәяси вакыйгалар тәрбияви процессның мөһимлеген күрсәтә. Без, югары дәрәҗәле белгечләр әзерләү өчен, зур акчалар тотабыз, алар ватаныбыз патриоты булмаса, бу нигә кирәк? Алар чит илгә китеп бетәчәкме?» – диде ректор. Аның сүзләренчә, тәрбия эше спорт һәм мәдәни чараларга гына кайтып калырга тиеш түгел. Студентларда илебезгә карата милләтпәрвәрлек хисләре тәрбияләргә кирәк. Казан университетының 210 еллык юбилее моның өчен менә дигән мөмкинлек булачак.

Аралашу вакытында ректорга күп төрле темаларга караган сораулар бирелде. Әйтик, студентлар үзләрен, беренче чиратта Казан федераль университеты, аннары нинди дә булса бүлек студенты буларак күрсәтсеннәр өчен, нишләргә, дигән сорауга җавап итеп: «Башта, аларны тәрбияләгәнче, безнең уку йортыбызның бер икәнен танырга кирәк!» – диде И.Гафуров. Шулай ук студентларга уку йортыбыз эчендә үз белемнәре белән акча эшләү мөмкинлеген булдыруга да басым ясалды.

Очрашуда һәр институт базасында, яшьләр арасында милләтпәрвәрлекне пропагандалау максатыннан, түгәрәк яисә махсус секцияләр оештыру теләге яңгырады. Шулай ук авылдан килеп белем алучы студентларның кайбер мәдәни чараларга бара алмавын да уңай якка хәл итү өчен тәкъдимнәр яңгырады.

Нәтиҗәдә, кураторлар өчен шундый очрашуларны ешрак оештыру, проблемаларны уртага салып хәл итү өчен мәйдан булдыру тәкъдиме хупланды. Шулай ук чарада «Академик төркемнең иң яхшы кураторы» бәйгесендә җиңүчеләрне дә зурладылар.




Влад Михневский фотолары

Галимнәребез

# Шәхеснең бөеклеге – мирасында!

Материалны **Ләйсән ИСХАКОВА** әзерләде

27-29 май көннәрендә КФУда Казан университеты профессоры, ТР ФА академигы, олуг тарихчы-галим Миркасыйм Госмановның (1934-2010) тууына 80 ел тулуга багышланган «Төрки-мөселман дөньясы: төңгәллек, мирас һәм өйрәнү перспективалары» дип исемләнгән халыкара фәнни конференция узды. Чара пленар һәм секция утырышлары, түгәрәк өстәл рәвешендә рус, татар һәм инглиз телләрендә барды.



Конференция кысаларында 27 май көнне узган секцияләрнең берсе «Тарихта шәхес: М.Г.Госмановның фәнни һәм иҗтимагый мирасы» дип аталды. Биредә галимнең элеккеге хезмәттәшләре, шәкертләре, күренекле тарихчылар, әдәбиятчылар чыгыш ясады. Утырышта М.Г.Госмановның кызы – КФУ профессоры Диләрә Госманова да катнашты.

Тарих, текстология, тел белеме, әдәбият, фәлсәфә, археология өлкәсендә үзеннән соң тирән эз калдырган олуг галим М.Госманов исеме университетыбыз тарихы битләренә дә алтын хәрефләр белән уеп язылган. Көнбатыш Кытайның Синьцзянь провинциясе өлкәсендәге Голҗа шәһәрендә туып үссә дә, егетне бабаларының ватаны, борынгы университетлы Казан шәһәре үзенә тарта. Шуңа да 1958 елда ул мәшһүр Казан дәүләт университетына укырга керә. Башта татар филологиясе бүлегендә белем ала, III курсны тәмамлагач, тарих-филология факультетының тарих бүлегенә күчерелә һәм СССР тарихы кафедрасында тарихи чыганаклар буенча белгечлек ала һәм шунда ук СССР тарихы кафедрасында эшкә кала. Башта гади укытучы булып эшләсә, 1983 елдан – кафедра мөдире, 1985-1991 елларда Казан университетының уку-укыту эшләре буенча проректоры булып тора. Тарих фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗә ала (1979).



Влад Михневский фотосы

М.Г.Госмановның укытучылык эшчәнлеге, традицион фәннәрдән лекцияләр уку белән беррәттән, Идел һәм Урал буе халыклары тарихын яктырткан чыганаклар, иске татар палеографиясе буенча яңа курслар әзерләү белән бәйләп алып барыла. Шул ук вакытта ул Евразиянең борынгы төрки дәүләтләре һәм халыклары тарихы буенча махсус курс укый. 1968 елдан алып 1985 елга кадәр Татарстан тарихы буенча белгечләр әзерләүгә җитәкчелек итә.

Галимнең фәнни-тикшеренү эшчәнлегенең төп юнәлеше исә XIII-XX гасыр башы Идел һәм Урал буендагы төрки телле халыклар тарихы һәм әдәбияты буенча гарәп графикасындагы төрки язма чыганакларны өйрәнү белән бәйле була. Аның фәнни эшчәнлегендә археографик эзләнүләр – шәрык телләрендәге язма истәлекләрне табу һәм туплау буенча экспедицияләр үткәрү, аларны өйрәнү зур урын алып тора. 1963 елда Казан университетында М.Г.Госманов инициативасы һәм идеясе буенча шәрык телләрендәге язма истәлекләрне җыю һәм өйрәнү өлкәсендә Казан ориенталистика мәктәбе традицияләрен яңарткан беренче экспедиция оештырыла. 1964 елдан алып 1989 елга кадәр М.Г.Госманов КДУның даими эшләп килә торган археография экспедициясен җитәкли. Экспедиция, көнбатышта Мәскәү янындагы Кострома һәм Касыйм якларыннан алып, көнчыгышта Иркутск өлкәсенә, төньякта Пермь-Нократтан алып, көньякта Әстерхан һәм Оренбургка кадәр төрле төбәкләрдә эш алып бара.

*КДУ проректоры буларак, М.Г.Госманов язма чыганакларны җыю, өйрәнү һәм бастыру өчен фәнни-тикшеренү археография лабораториясе, 1989 елда ачылган татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетында берничә тарих-филология кафедрасы, экология факультетлары оештыруда якыннан торып катнаша. Ул Казан университетында шәрык телләре бүлекчәләрен торгызуга зур өлеш кертә. Аның катнашында чит ил (Венгрия, ГФР, Кытай, Төркия) университетлары белән элемтәләр урнаштырыла.*

Җитмешенче еллардан башлап, язучы-галим, укучы яшьләр арасында тарих фәнен киңрәк пропагандалау максаты белән фәнни-популяр жанрга мөрәҗәгать итеп, «Серле балбал», «Таулар, үзәннәр иленә сәяхәт» исемле китапларын бастыра. 1963 елдан башлап, ул борынгы кульязмаларны җыю буенча илнең төрле почмакларына археографик экспедицияләр оештыра башлый һәм әлеге хезмәт 1983 елда «Каурый каләм эзеннән» исеме белән басылып чыга. М.Госманов татар әдәбияты классикларының әсәрләрен басмага әзерләү эшендә якыннан катнаша: шагыйрь Акмулла, татар шагыйре Кол Гали һәм Габдрәхим Утыз-Имәни әл-Болгари әсәрләре басмасының редакторы була. Әмма аны белгән, аның белән аралашкан кешеләр күңеленә ул, иң беренче чиратта, олы йөрәкле, гадел, тирән фикерле, зирәк акыллы кеше, олуг остаз булып кереп калган. «Ходай Тәгалә аңа сәләтне чеметеп түгел, кушучлап биргән. Ул хезмәт сөючән, тырыш кеше иде. Һәм ул бу сыйфатларны хезмәттәшләре, студентларыннан да таләп итте. Шуңа да аның янына тырыш, тырыш булмаса да, тырышлыкка омтылучан асыл егетләр, кызлар җыела иде», – дип искә ала КФУ профессоры Х.Й.Миңнегулов. Бүген дә тарихчы-галимнең йөзләгән шәкерте академик Миркасыйм Госмановның укучысы булуы белән горурланып яши.

***ТР Милли Китаханәсе сайты материаллары файдаланылды***

Студент тормышы

# Табигать белән ярыштык

**Алинә САДЫЙКОВА**

Ял көннәрен студентлар ничек үткәрә? Дөресрәге, ничек үткәрергә тиеш? Бу сорауга җавапны КФУстудентлары бик яхшы белә.



Яр Чаллы институтының «Дубравушка» спорт сәламәтләндерү лагере һәм «Нижняя Кама» Милли паркы территориясендә 22-23 май көннәрендә КФУ студентлары һәм аспирантлары арасында туристлар слеты уздырылды. Анда уку йортыбыздан 8 команда җиде төрле ярышта: фигуралы йөрү, велотриал, юнәлешне билгеләү, җәяүле дистанция, сулы дистанция, стенгазета, визиткада үз көчләрен сынады. Чарада катнашкан географик һәм экологик белем бирү бүлегенең «Җиде румб» турклубы командасы вәкилләре бу ярыш турында фикерләрен безнең игътибарга да тәкъдим итте.



• *Динара Хакимова, 3 курс студенты:*

«Турслет ул – минем өчен яхшы ял, яңа сыйфатларымны ачу, креатив кешеләр белән танышу, аралашу. Командабыз әле тәҗрибәсез булса да, ул максатчан, дус һәм тату. Каршылыкларны бергәбергә җиңеп чыктык һәм финишка кадәр барып җитә алдык. Бу мизгелдә командабыз инде бер бөтен иде. Шушы ике көн эчендә позитив эмоция, бәяләп бетергесез тәҗрибә алдык. Учак янында төнге 2гә кадәр җырлап утырулары гына да ни тора бит! Төнге матурлык, йолдызлы күк йөзе, бик яхшы компания, дәртле җырлар... Җитәкчебез Рөстәм Шәрип улы Фәрхуллинга, турслетны оештыручыларга һәм командама тормышымдагы шушы ике көн өчен зур рәхмәт!»

• *Диләрә Локманова, 1 курс студенты:*

«Кызык һәм шул ук вакытта тынгысыз ике көн һәм учак янындагы гиталалы төн! Бу – КФУның «Дубравушка»дагы турслеты! Ике көн буе без призлы урын өчен көрәштек: велосипедларда, телевизордангына күреп белгән байдаркаларда, катамараннарда ярыштык, автоматны сүтеп-җыйдык, агачның биеклеген хисапладык, учак яктык һ.б. Без әле алгы рәтләрдә бардык, әле башка командалардан калыштык, әмма, бернигә дә карамастан, сүзләр белән генә әйтеп бетермәслек хискичерешләр, адреналин алдык!»

• *Зөлфәт Галәветдинов, 1 курс студенты:*

«Миңа бу яллар бик ошады. Бар да искиткеч булды: студентлар мохите, гүзәл табигать, мавыктыргыч уеннар, ярышлар. Мондый чаралар күбрәк булсын иде! Алар студентларга үзләре дә белмәгән сәләтләрен ачарга ярдәм итә».

• *Вероника Имаева, 3 курс студенты:*

«Дубравушка» ял итү базасына минем инде кире кайтасым килә! Бәйгедә катнашучылар барысы да нык торучанлык, чыдамлык сәләтләрен һәм үзләренең иң яхшы күнекмәләрен күрсәтте. Иң ахыргы бәйгедә командабызның икенче сулышы ачылды һәм сулы дистанцияне без җырлап диярлек үттек. Мондый ярышта беренче тапкыр катнашуым, соңгысы да булмастыр дип уйлыйм. Барлык катнашучыларга әлеге спорт төрендә уңышлар телим!»

• *Эльвир Зәйнетдинов, 5 курс студенты:*

«Төп бәйгеләрдә җиңелсәк тә, слет бик яхшы узды. Мин спорт белән инде берничә ел шөгыльләнәм һәм бер мизгелгә туризм белән мавыкмаганым өчен үкенеп тә куйдым. Урман буенча адашып йөрүләребез, шул рәвешле үз хаталарыбызны табып, аларны төзәтүләребез команданы берләштерде һәм ныгытты. Сулы дистанцияне әйтеп тә тормыйм! Табигать белән көрәшүе бик авыр икән, бу иң катлаулы һәм куркыныч ярышларның берсе булды. Нәкъ менә шундый ярышлар вакытында студент тормышының тәмен татыйсың, университетыңа гашыйк буласың. Рәхмәт, КФУны бик яратам!!

• Милли мирас







**Гүзәлия ГЫЙНИЯТУЛЛИНА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

23 май көнне Татар бистәсендә Печән базары ярминкәсе узды. Аны Бөтендөнья татар яшьләре форумы «Ялкын» журналы белән берлектә оештырды. Быел чара «Ялкын» журналының 90 еллык юбилеена багышланды.

# «Печән базары» XX йөз башына алып кайта

Ярминкә тулаем XX гасыр рухына туры китереп оештырылды – кунаклар бөек шагыйрь Габдулла Тукай яшәгән вакытларга сәяхәт итте һәм үзләрен шул чор кешесе итеп тойды. Чара үз заманында татар дөньясының үзәге булып саналган Иске Татар бистәсендә, Мәрҗани мәчете тирәсендә үткәрелде. Бәйрәм иртәнге тугыздан кичке җидегә кадәр барды. Якында гына Мәрҗани һәм Апанай мәчетләре урнашкан булгач, ярминкәгә намаздан чыгучылар да кушылды.

Бу чарадан безнең КФУ студентлары да читтә калмады, кайберләре хәтта оештыручы буларак та катнашты. Бу, әлбәттә, яшьләрнең милли чаралар белән кызыксынулары, җәмгыятьтә барган вакыйгаларга битараф булмаулары турында сөйли.

Акциядә катнашуның төп шарты: һәр кунакның киемендә милли элемент булырга тиеш иде. Катнашучылар бу шартны җиренә җиткереп үтәде дияргә мөмкин. «Чарага барысы да XX йөз башы рухын хәтерләткән киемнәрдән килде. Без татар милли киемен алъяпкыч кигән кызлар итеп кенә күзаллауны бетерү яклы. Киемнәрне бүген дә заманчалаштырып киеп йөрергә була, дип күрсәтергә телибез», – ди Бөтендөнья татар яшьләре форумы делегаты Ленария Мөслимова.

Бу көнне Татар бистәсендә театральләштерелгән ярминкә һәм уку паркы да эшләде. Паркта махсус киштәләр куелып, анда татар китаплары алмашу мөмкинлеге тудырылды. Теләгәннәр Кабан күле буенда рәхәтләнеп китап укып утырды. Шулай ук бистәнең ишек алларында язучылар белән очрашулар, китап презентацияләре, шигырь уку, музыкаль чыгышлар оештырылды.

«Печән базары»нда милли киемле, калфаклы кызлар, түбәтәйле егетләр, сәүдәгәрләр, зәркән осталары, читек тегүчеләр, икмәк пешерүчеләр, сөлге тукучылар, чигүчеләр – кырыктан артык кул остасы бар иде. Шулай ук шәһәребездә һәм башка төбәкләрдә укучы студентлар тарафыннан ясалган сувенирлар, милли ризык, сәнгать әсәрләре, кул эшләре, төрле китаплар тәкъдим ителде.

Форум рәисе урынбасары Гөлназ Бәдретдин сүзләренчә, алар татар милли чарасын киң җәмәгатьчелеккә танытырга тели.

Мондый бәйрәмнәр безнең җәмгыятебезгә бик кирәк. Булган традицияләрне саклау, яңаларын кертү – безнең бурыч бит!

• Соңгы кыңгырау

# Өч ел һәм КФУ дипломы

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

Психология һәм мәгариф институтының башлангыч белем бирү методикасы һәм педагогика кафедрасы студентлары өчен быелгы Соңгы кыңгырау бәйрәме үзенчәлекле булды. Бәйрәм тантаналы төстә, күтәренке рухта үтте.

Чарада ике белгечлек буенча дипломнар тапшырылды. Чыгарылыш шуның белән үзенчәлекле: 2011 елда старт алган урта махсус белем бирү программасы быел үзенең беренче карлыгачларын чыгарды. «Әле кайчан гына КФУга укырга кердек, дип шатланып йөри идек, хәзер менә университет белән саубуллашыр вакыт та килеп җитте», – ди башлангыч сыйныфлар укытучысы белгечлеген үзләштергән кызлар.

Соңгы кыңгырау бәйрәме – мәктәпне тәмамлаучы укучылар өчен дә, студентлар өчен дә бик истәлекле, шатлыклы һәм шул ук вакытта моңсу бәйрәм. Шуңа да карамастан, кечкенә студентлар өчен хәзер бөтен ишекләр, мөмкинлекләр дә ачык. Алар шәхес буларак кына түгел, ә белгеч буларак та даими үсеш процессында булган абруйлы Психология һәм мәгариф институты белән бергә формалашты. Ә бу, үз чиратында, студентларга төпле белем биргән укытучыларның тырыш хезмәт нәтиҗәсе. Бәйрәмдә остазларга карата бары тик рәхмәт сүзләре генә яңгырады. Чарада шулай ук чыгарылыш – бишенче курс студентлары да катнашты. Һәр студент үзенә күрә күркәм һәм кабатланмас: кемдер иптәшләре арасында диета тотучы, кемдер параларга йөрмичә сессияне башкаларга караганда да беренче һәм яхшырак бирүче, ә кемдер лекцияләр вакытында да татлы «булочкалар» турында хыялланучы студент булып истә калачак. Һәр студент аерым бер номинациядә мактау кәгазе белән бүләкләнде. Укытучылар өчен дә искәрмә булмады: студентлар аларны да аерым номинацияләрдә билгеләп үттеләр. Бәйрәмдә студентлар үзләренең төрле кызыклы истәлекле фотоларыннан ясалган видеороликлар тәкъдим иттеләр. Аларның һәркайсы студент тормышының искитмәле кызык һәм мавыктыргыч булуын кат-кат искәртте.

Студентлар уку дәверендә өйрәнгән осталыкларын, сәләтләрен күрсәтте. Мәсәлән, алар команан бик матур итеп рәсем ясадылар. Бәйрәм кызыклы мизгелләр, җырбию белән үрелеп барды. Җылы атмосферада узган чара студентлар күңелендә якты хатирә булып озак сакланыр.

Кино карарга яратасызмы? Үзләре фильм төшергән яшь режиссерлар, операторлар, актерлар белән аралашасыгыз киләме? Алайса, без сезне үзебезнең чыгарылыш кичәбездә көтеп калабыз!

**Программада** – музыка, фотосессия, кызыклы бәйгеләр, фильмнар карау һәм тамашачыларның тавыш бирүе.

**Кайчан?** 29 май 18:00. **Кайда?** «Мир» кинотеатры (Достоевский ур., 30)

**Үзең белән нәрсә алып килергә?** Әлбәттә, яхшы кәеф һәм киноиндустрия дөньясына керү әзерлеге. Керү ирекле.

**«Точка.кино»** Казан мәктәбенең бу инде дүртенче чыгарылышы. Биредә кино сәнгате белән кызыксынучылар, кино төшерергә теләгән кешеләр җыелган. Укыту өч юнәлештә бара: режиссер, актер, оператор. Шулай ук уку дәверендә дөнья һәм Россия кинематографиясе тарихы буенча лекцияләр, семинарлар, төрле кызыклы мастер-класслар (операторлык сәнгате, психология, ораторлык сәнгате һ.б.) уза.

Киномәктәп кысаларында балалар өчен оештырылган **«КиноСадик»** сәнгать остаханәсе үз эшчәнлеген актив алып бара. Балалар кечкенә яшьтән рәсем, бию, җыр, костюмнар, декорацияләр ясау аша кино дөньясы белән танышалар, үзләре үк актер, режиссер, оператор вазыйфаларын башкарып, беренче фильмнарын да төшерләр.

Тулырак мәгълүматны сез сайтта (*tochka-kino.ru*) һәм социаль челтәрдә (*vk.com/tochka.kino*) таба аласыз. Рәхим итегез!

• Киңәш-табыш

# 100% игътибар = 100% нәтиҗә!

**Ләйсән ИСХАКОВА** киңәшләре

Нинди дә булса әһәмиятле эш яки йөкләмәне тиз арада эшләргә кирәк булганда, без еш кына башка, алай ук кирәк булмаган шөгыльләргә бүленергә яратабыз. Баксаң, бу начар гадәттән котылырга мөмкин икән! Нибары берничә гап-гади кагыйдәне генә үтәргә кирәк.

## МАКСИМУМ КОНЦЕНТРАЦИЯ

- Иң элек эш өчен уңайлы шартлар тудырылсын. Якыннарыгыз, дусларыгыздан сезне бүлдермәүләрен сорагыз.
- Эшне периодлап үтәү яхшы нәтиҗәләр бирә: 1 сәгать эш һәм 10 минут ялны чиратлаштырырга мөмкин. Әлбәттә, башта 1 сәгать буе бернигә дә бүленмичә эшләү җиңел булмаячак. Шулай да түзәргә кирәк.
- Үзебезне психологик яктан әзерлибез. Әһәмиятле эштән бүлдерүче тышкы факторларны юкка чыгаргач, эчкеләреннән дә котылабыз. Бу эшне үтәү сиңа нигә кирәк? Доклад – автомат имтихан алу, ә диплом эшен язу узган 4 ел вакытның бушка узмавын исбатлау өчен кирәк!
- Эшне булдыра алган кадәр иртәрәк башлау хәерле. Болай эшләү эшнең нәтиҗәлелеген тагын да арттырачак. Өстәвенә вакытыннан алда беткән эш койрыкларсыз тормыш вәгъдә итә.
- Киләсе көн планын бүген үк уйлап куй. Үзеңне: «Бүген мин көчемнән килгәннең барысын да эшләячәкмен, биремнәрне аерым бер кызыксыну белән үтәячәкмен», – дип ышандыр. Болай итү эшкә керешкәнче, булган бөтен куркуны юк итеп, үз-үзеңә ышаныч өстәячәк.

## ЭШ УРЫНЫ

Тирә-ягыңа кара. Юылмаган чынаяк, кирәкмәгән дәфтәрләр аунап ятмыймы? Принстон университеты галимнәре шуны ачыклаган: эш урынындагы (хәтта электрон почтадагы!) тәртипсезлек, җыйнаксызлык игътибарны читкә юнәлтә, стресс тудыра һәм файдалы эш коэффициэнтын бермә-бер киметә икән!

## ТӘНӘФЕС

Эшне тәнәфес белән чиратлаштырырга кирәклеге турында белгечләр дә әйтә. Ә ул тәнәфесне ничек үткәрергә? Иң яхшы ял чарасы – башка эшкә күчү. 5-10 минут ял вакытын файдалы һәм нәтиҗәле итеп менә ничек үткәрергә була:

- ***Музыка.*** 1-2 яраткан җырыңны тыңлап ал, кушылып җырлау да комачау итмәс. Бу бераз ял итеп алу һәм кәефне күтәрү өчен менә дигән чара.
- ***Видео.*** Әмма теләсә нинди күңел ачуга корылган видео карау киңәш ителми. Нинди дә булса файдалы эшкә, иҗатка рухландыра, илһамландыра торган видеоязма карап ал.
- ***Физкультура.*** Бер урында озак вакыт утырып тору ардырып кына калмый, сәламәтлеккә дә зыян сала. Шуңа тәнәфесне физик күнегүләргә багышлау да әйбәт булыр.
- ***Рәсем.*** Ходай сиңа рәсем ясау сәләтен бирмәсә дә, блокнотка нинди дә булса рәсем-сызым төшерү стресстан котылырга һәм башны ял иттерергә ярдәм итә.
- ***Аралашу.*** Якын кешең, дустың яки хезмәттәшең белән сөйләшеп яки язышып ал. Болай эшләү дә шәп кәеф, позитив рух өстәячәк.
- ***Планлаштыру.*** Буш вакыт булганда, эшләреңне тәртипкә сал, көннең калган өлешендә яисә иртәгә хәл ителергә тиешле мәсьәләләрне теркәп кую да комачауламас. Болай итү эшегезнең максатчанлыгын һәм нәтиҗәлелеген арттырыр.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.